ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.07.2020 Казан шәһәре № 71-2/тко-2020

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең «Экопарк» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыклар эшкәртүгә 2020 елга чик тарифлар билгеләү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифлар хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең «Экопарк» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыклар эшкәртүгә әлеге карар кушымтасына туры китереп, чик тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик дәрәҗә тариф карар үз көченә кергән көннән башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Каты коммуналь калдыкларны эшкәртүне гамәлгә ашыручы «Экопарк» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тариф билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көненнән соңга калмыйча, ирекле файдаланырга тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.П.Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 22.07.03.2020 № 71-2/тко-2020 карарына кушымта

«Экопарк» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыклар эшкәртүгә чик тариф.

| № т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыклар эшкәртүгә чик тариф, сум/куб.м (өстәмә хак салымыннан башка) |
|---|---|---|
| | | карар гамәлгә кергән көннән башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге | |
| 1 | «Экопарк» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 75,01 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге